СОВЕТ
БОЛЬШЕТИГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.05.2020 Зур Тигәнәле авылы № 151

**Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
Зур Тигәнәле авыл җирлегендә
Бюджет корылышы һәм бюджет
процессы турындагы нигезләмәнең
аерым пунктларының гамәлдә
булуын туктатып тору турында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 01 апрелендәге 103-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү максатларында

**Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге карары белән расланган Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлегендә Бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәнең 2015 елның 26 гыйнварындагы 89а номерлы (вакытлар өлешендә) 32 маддәсендәге 3 пунктының 1 абзацының, 2 пунктының, 18 маддәнең 3 пунктының, 2 пунктының гамәлдә булуын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга һәм Зур Тигәнәле авыл мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Алексеевский районы, Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал урамы 17 йорт; “Әшнәк” кибете бинасында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Алексеевский районы, Әшнәк авылы, Х.Вахит урамы, 11 йорт махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.Җ.Әхмәтҗанов**